# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлегенең Балтамак авылы торак пунктында граждannар җыены
нәтиҗәләре турында

**22 ноябрь 2022 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 22 ноябрендә 13.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2023 елда 8000 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

- Балтамак авылы зираты территориясен койма белән әйләндерү өчен материаллар сатып алу;
- Балтамак авылы зиратына ритуаль кирәк-яраклар саклау будкасы төзү өчен материаллар сатып алу һәм эшләр өчен түләү;
- Балтамак авылларында кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 12 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 10 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 10 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Рангазар авыл жирлегенең Бал-Тамак авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2023 елда 8000 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- Балтамак авылы зираты территориясен койма белән әйләндерү өчен материаллар сатып алу;
- Балтамак авылы зиратына ритуаль кирәк-яраклар саклау будкасы төзү өчен материаллар сатып алу һәм эшләр өчен түләү;
- Балтамак авылларында кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Рангазар авыл җирлегенең Рангазар мәгълүмати

стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче А.Р.Шарипова